**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№ М 234**
**02.05.2024**

Шәһәр Хакименең 2018 елның 9 июлендәге М 299 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 гыйнварындагы 71 номерлы Указы нигезендә, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пунктына туры китереп,

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2018 елның 9 июлендәге М 299 номерлы Карары белән (шәһәр Хакименең 2021 елның 27 декабрендәге М 529 номерлы Карары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) коррупциягә каршы тору максатында, җирле үзидарә органының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау турында яки җайга салу турында таләпләр, «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, башка федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр) белән билгеләнгән йөкләмәләр үтәлешен тәэмин итүдә;»;

2) 15 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктча өстәргә:

«6) муниципаль хезмәткәргә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәүгә комачаулый торган, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килү турында хәбәр итү.»;

3) 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның бишенче абзацында һәм 6 пунктчасында күрсәтелгән белдерү кәгазьләре җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе яисә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны

профилактикалау эше өчен җаваплы һәм белдерү кәгазьләрен карау нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмәләр әзерләүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи заты тарафыннан карала.»;

4) 21 пунктта «15 пунктның 5 пунктчасында» сүзләрен «15 пунктның 5 һәм 6 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

5) 22 пунктта:

- 1 пунктчада «15 пунктның 5 пунктчасында» сүзләрен «15 пунктның 5 һәм 6 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

- 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 2 пунктчаның икенче һәм бишенче абзацларында һәм 5 һәм 6 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яки белдерү кәгазьләрен алдан карау йомгаклары буенча нигезле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 32, 35, 36.1, 38 пунктлары нигезендә карарларның берсен яки башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

6) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының 5 һәм 6 пунктчаларында күрсәтелгән белдерү кәгазьләре, комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.»;

7) 26 пунктта «15 пунктның 2 пунктчасы» сүзләрен «15 пунктның 2 һәм 6 пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

8) 27 пунктның 1 пунктчасында «15 пунктның 2 пунктчасы» сүзләрен «15 пунктның 2 һәм 6 пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

9) түбәндәге эчтәлектәге 36.1 пункт өстәргә:

«36.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган шартлар барлыкка килү һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәве мөмкин булмау арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуны танырга;

2) муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган шартлар барлыкка килү һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәве мөмкин булмау арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмауны танырга.»;

10) 37 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы 1, 2, 4, 5 һәм 6 пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, нигезләр булган очракта, комиссия әлеге Нигезләмәнең 30-36.1 һәм 38 пунктларында каралган карарлардан тыш, башка карар кабул итәргә мөмкин. Шундый карар кабул итү нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев